| | | |
|---|---|---|
| «РАССМОТРЕНО» | «СОГЛАСОВАНО» | «УТВЕРЖДАЮ» |
| Руководитель ШМО | Зам. директора по УР | Директор МБОУ «Лашманская СОШ» |
| ____________/Минубаева М.Н./ | ____________/Зиганшина М.И./ | ____________/Нуртдинов Н.Р./ |
| Протокол №1 от «27» августа 2022 г. | «29» августа 2022 г. | Приказ № 25 от «31» августа 2022 г. |

**АДАПТИРОВАННАЯ РАБОЧАЯ ПРОГРАММА**

по учебному предмету «Родной (татарский) язык и родная (татарская) литература»
основного общего образования 5 класс
учителя I квалификационной категории
МБОУ «Лашманская СОШ»
Черемшанского муниципального района Республики Татарстан

Гайсиной Гузалии Идрисовны

## Основные документы, используемые при составлении рабочей программы:

- Закон «Об образовании в Российской Федерации» № 273-ФЗ от 29.12.2012;
- Федеральный государственный образовательный стандарт образования обучающихся с умственной отсталостью (интеллектуальными нарушениями), утвержденный приказом Минобрнауки России от 19.12.2014 № 1599;
- Федеральный перечень учебников, рекомендуемых к использованию при реализации имеющих государственную аккредитацию образовательных программ начального общего, основного общего, среднего общего образовании (рег. 14.09.2020 № 59808);
- Закон Республики Татарстан от 22.07.2013 № 68-ЗРТ (ред. от 23.07.2014) «Об образовании»;
- Примерная адаптированная основная общеобразовательная программа для обучающихся с умственной отсталостью (интеллектуальными нарушениями), программа одобрена решением ФУМО по ОО (протокол от 22.12.2015 № 4/15);
- Основная образовательная программа основного общего образования МБОУ «Лашманская СОШ» на 2022-2023 г.;
- Учебный план МБОУ «Лашманская СОШ» на 2022-2023 г. (утв. приказом № 2 от 31.08.2022);
- Положение о рабочей программе принятой на заседании педагогического совета МБОУ «Лашманская СОШ» (протокол №1 от 29.08.2022 и утвержденного директором школы приказ № 25 от 31.08.2022)

## Рабочая программа ориентирована на учебник:

Р. З. Хайдарова, Р. Һ. Рангулова " Татарский язык и литературное чтение". Учебник для 2 класса четырехлетней начальной школы с русским языком обучения". Казань. Издателство, "Магариф", 2009.

# АҢЛАТМА ЯЗУЫ

Татар теле Коррекцион мәктәпләрдә физик һәм акыл ягыннан зәгыйфь балаларны татар теленә өйрәтү гадиләштерелгән практик характерда алып барыла. Бу чорда билгеле бер система һәм эзлекле күчемлелек булырга тиеш. Татар телен өйрәтүдә иң мөһим бурычлар: 1. Грамоталы язарга өйрәтү.
2. Үз фикереңне дөрес итеп әйтә һәм яза белергә өйрәтү.
3. Сөйләм телен үстерү.
4. Балаларнык гомуми үсешен булдыру.
5. Укучыларның тирә-яктагы чынбарлык белән танышулары, күзәтүләре нигезендә аларда чынбарлык турында элементар, дөрес фикерләү формалаштыру.
6. Өйрәнелә торган материалны анализлау, чагыштыру, гомумиләштерү.
7. Балаларда эш сөючәнлек һәм мөстәкыйльлек тәрбияләү.
Төп максат булып укучыларның сөйләм телен һәм фикерләү сәләтен төзекләндерү тора. Балалар тактадан, китаптан дөрес итеп күчереп язу кунекмәләрен, диктантлар язарга, язганны тикшерә һәм ялгышларны төзәтә белергә тиешләр. Укучыларның барча төр язулары пөхтә, график анык, дөрес һәм матур булырга тиеш. Контроль эшләргә - контроль күчереп язу, контроль диктантлар (аңлатмалы, күрмә, иҗади, сүзлек, һ.б.) керә. 3-4 сыйныфларда күчереп язу 5 нче -9 нчы сыйныфларда диктантлар язу таләп ителә. Ләкин һәрбер сыйныфта фикерләү сәләтенә карап, укучыларга шәхси биремнәр бирелә. Үтелгән кагыйдәләр буенча контроль диктантлар белән грамматик биремнәр дә бирелергә мөмкин. Укучыларны күнегү һәм биремнәрне аңлап эшләргә өйрәтү бик мөһим. Логопедка йөрүче балаларга зур игьтибар бирелергә тиеш (алар контроль диктант язудан азат ителмиләр, ләкин шәхси үсеш үзенчәлекләрен истә тоту зарур).
Якынча язма эшләр күләме.
Сузлек диктанты: IV нче сыйныф —1-5 сүз Vсыйныф -5-6 сүз VI сыйныф -5-10 сүз VII сыйныф -10-15 сүз VIII сыйныф - 15-20 сүз IX сыйныф - 20-25 сүз Контроль диктант: IV сыйн. - күчереп язу (30 сүз) Vсыйн. - 30-35 сүз VI сыин. - 35-40 сүз VIIсыйн. -40-45сүз VIII сыйн. - 45-50 сүз IXсыйн. -50-55 сүз
Контроль диктантларны бәяләү нормалары:
"5" орфографик һәм пунктуацион хата — 1/1,01, 0/2 булганда. "4" орфографик һәм пунктуацион хата — 2/3,1/2 булганда "3" орфографик һәм пунктуацион хата — 3/2, 3/3,4/3 булганда "2" орфографик һәм пунктуацион хата алдагы нормадан күбрәк булса. 1-2төзәтү яки 1 пунктуацион хата саналмый, үтелмәгән кагыйдәләр буенча жибәрелган хата хатага саналмый. Диктантта 1 хатага саналу очраклары: 1. Хаталарны бер үк сүздә кабатлау. 2. Сүздә бер үк хәрефне ике тапкыр кабатлау. 3. Сүзне язып бетермәү. 4. Сүзне җөмләдә ике тапкыр кабатлау. Уку Коррекцион мәктәп балаларны һәрьяклап үстерүгә зур игьтибар бирергә тиеш. Программаның: "Уку һәм сөйләм үстерү" булеге " Грамотага өйрәтү" өлешенең дәвамы булып тора. Уку дәресләре аерым предмет булып 4 нче сыйныфтан керә баш- лый. 1-3 сыйныфларда сөйләм телен үстерүгә зур басым ясала. Балаларны дөрес, аңлап, йөгерек һәм сәнгатьле укырга өйрәтү бурыч булып тора. Аңлаешлы текстларны эчтән һәм кычкырып укырга өйрәнүгә зур игьтибар бирелә. Текст эчтәлегенең эзлеклегенә, аңлашылган фикерләрнең бәйләнешен аңларга күнектерелә. Дөрес уку күнекмәләренә зур игътибар ителә, чөнки акыл ягыннан зәгыйфь балаларга бу бик авыр бирелә. Сөйләм культурасына таләпләр үсә бара. Укучылар 6 -9 нчы сыйныфларда текст эчтәлеген мөстәкыйль сөйләргә, аның планын төзергә, шулай ук

хикәядә чагыштырылган төп фикерне аңлый белергә тиеш. Шуның белән бергә, әсәрнең эчтәлеген тулысынча сөйләү, сайлап һәм кыскача сөйләү күнегүләре системалы рәвештә алып барыла. Иллюстрацияләр белән эшләү балаларның акыл эшчәнлеген үстерә һәм кимчелекләрен төзәтә. Бөтен эш төрләре сыйныфтан-сыйныфка катлауландырыла һәм укытучы ярдәмендә алып барыла.

**Укытуның көтелгән нәтиҗәләре**

**Шәхескә кагылышлы нәтиҗәләр:**

-шәхесара һәм мәдәниятара аралашуда татар теленә карата ихтирамлы караш булдыру һәм аны яхшы өйрәнү теләге тудыру;
-әхлакый кагыйдәләрдә ориентлашу, аларны үтәүнең мәҗбүрилеген аңлау;
-әдәби әсәрләрдәге төрле тормыш ситуацияләренә һәм геройларның гамәлләренә гомүмкешелек нормаларыннан чыгып бәя бирү;
-“гаилә”, “туган ил”, “мәрхәмәтлелек”, төшенчәләрен кабул итү,укучыда “башкаларга карата түземлелек, кайгыртучанлык”, “кеше кадерен белү”кебек хисләр формалашу.

**Метапредмет нәтиҗәләре:**

Төп гомуми белем бирү баскычында татар теле һәм әдәбиятын укыту,танып белү чарасы буларак, укучыларның фикер йөртү, интеллектуаль һәм иҗади сәләтләрен үстерүгә, шулай ук, реаль тормышта туган проблемаларны хәл итү өчен кирәк булган универсаль уку гамәлләрен (танып белү, регулятив, коммуникатив) формалаштыруга хезмәтитә.

Укучыларда мәгълүмати җәмгыятьтә яшәү һәм эшләү өчен кирәкле күнекмәләр үстерелә. Укучылар текст, күрмә-график рәсемнәр, хәрәкәтле яисә хәрәкәтсез сурәтләр, ягъни төрле коммуникацион технологияләр аша тапшырыла торган мәгълүмати объектлар белән эшләү тәҗрибәсе ала; презентацион материаллар әзерләп, зур булмаган аудитория алдында чыгыш ясарга өйрән*ә; у*кучыларда, компьютер яисә МКТнең башка чаралары белән эшиткәндә,сәламәтлеккә зыян китерми торган эш алымнарын куллана алу күнекмәләре формалаша.

**Танып-белү гамәлләре**:

-фикерләүне үстерү белән бәйле психик функцияләр: логик фикерләү,сәбәп- нәтиҗә бәйләнешләрен табу, индуктив, дедуктив фикерли белү;
-иҗади һәм эзләнү характерындагы проблеманы билгеләү, аларны чишү өчен алгоритм булдыру;
-объектларны чагыштыру, классификацияләү өчен уртак билгеләрне билгеләү;
-төп мәгълүматны аеру, укылган яки тыңланган мәгълүматның эчтәлегенә бәя бирә белү;
-тиешле мәгълүматны табу өчен, энциклопедия, белешмәләр, сүзлекләр,электрон ресурсларкуллану.

**Регулятив гамәлләр:**

-дәрескә кирәкле уку-язу әсбапларын әзерли һәм алар белән дөрес эш итәбелү;
-дәрестә эш урынын мөстәкыйль әзерли белү һәм тәртиптә тоту күнекмәләрен үстерү;
-уку хезмәтендә үзеңә максат куя, бурычларны билгели белү;
-эш тәртибен аңлап, уку эшчәнлеген оештыра, нәтиҗәле эш алымнарын таба белү;
-уку эшчәнлеге нәтиҗәләрен контрольгә ала белү;

-билгеләгән критерийларга таянып, эш сыйфатына бәя бирә белү;
-укудагы уңышларның, уңышсызлыкларның сәбәбен аңлый, анализлый һәм,кирәк булганда, төзәтмәләр кертә белү;
-ихтыяр көче, максатчанлык, активлык кебек сәләтләрне формалаштыру.

**Коммуникатив гамәлләр:**

-әңгәмәдәшеңнең фикерен тыңлый, аңа туры килерлек җавап бирә белү;
-әңгәмәдәшең белән аралашу калыбынтөзү;
-аралаша белү сәләтен үстерү (аралашучанлык, хислелек, эмпатияхисләре);
-парларда һәм күмәк эшлибелү;
-мәгълүматны туплау өчен, күмәк эшчәнлектә катнашу;
-әңгәмәдәшең белән сөйләшүне башлый, дәвам итә, тәмамлый белү.

**Предмет нәтиҗәләре**:

-укучыларның коммуникатив компетенциясен (аралашу осталыгын) үстерү,ягъни татар телендә сөйләшүчеләр белән телдән яки язмача аралашукүнекмәләре булдыру;
-коммуникатив бурычлар куя һәм хәл итә белү, адекват рәвештә арашуның вербаль һәм вербаль булмаган чараларыннан, сөйләм этикеты үрнәкләреннән файдалана алу, итагатьле һәм киң күңелле әңгәмәдәш булу;
-“Татар теле һәм әдәбияты” предметына карата уңай мотивация һәм тотрыклы кызыксыну булдыру һәм шулар нигезендә белем алуның алдагы баскычларында татар телен уңышлы -шәхесара һәм мәдәниятара аралашуда татар теленә карата ихтирамлы караш булдыру һәм аны яхшы өйрәнү теләге тудыру;
-әхлакый кагыйдәләрдә ориентлашу, аларны үтәүнең мәҗбүрилеген аңлау;
-әдәби әсәрләрдәге төрле тормыш ситуацияләренә һәм геройларның гамәлләренә гомүмкешелек нормаларыннан чыгып бәя бирү;
-“гаилә”, “туган ил”, “мәрхәмәтлелек”, төшенчәләрен кабул итү,укучыда “башкаларга карата түземлелек, кайгыртучанлык”, “кеше кадерен белү”кебек хисләр формалашу.

ПРОГРАММА МАТЕРИАЛЫН ҮТҮ ӨЧЕН ТӘКЪДИМ ИТЕЛГӘН ДӘРЕСЛЕКЛӘР:

I сыйныф. Татарча сөйләшергә өйрәнәбез. -Чаллы, 1992. Татарча сөйләргә, укырга һәм язарга өйрәнәбез. А.Ш.Асадуллин.
II сыйныф.Әлифба. Р.Г.Вәлитова, С.Г.Вагыйзов.
Ш сыйныф. Татар теле. Ф.Ю.Юсупов, В.З.Гарифуллин, Л.К.Новикова.
IVсыйныф. Туган тел. С.Г.Вагыйзов, Р.Г.Вәлитова 1 нче сыйныф. Татар теле. С.Г.Вагыйзов, Р.Г.Вәлитова 1 нче сыйныф.
V сыйныф. Р.З.Хәйдәрова, Р.Һ. Рангулова. Татар теле һәм уку китабы. 2нче сыйныф. Казан “Мәгариф” нәшрияты 2009
VI сыйныф. . Р.З.Хәйдәрова, Р.Һ. Рангулова. Татар теле һәм уку китабы. 3 нче сыйныф
VII сыйныф. Р.З.Хәйдәрова, Р.Һ. Рангулова. Татар теле һәм уку китабы. 4 нче сыйныф.
VIII сыйныф. . Р.З.Хәйдәрова, Р.Һ. Рангулова. Татар теле һәм уку китабы. 5 нче сыйныф
IX сыйныф. . Р.З.Хәйдәрова, Р.Һ. Рангулова. Татар теле һәм уку китабы. 6 нче сыйныф

***Программаның эчтәлеге.***

| № | Бүлекләр, темалар | Сәгать саны | Темага караган төп төшенчәләр |
|---|---|---|---|
| 1 | Яңа уку елы белән! | 23 | “Мәктәп” темасына бәйле сүзләрне һәм җөмләләрне искә төшереп, диалогик сөйләм оештыру күнекмәләрен активлаштыру. Бирелгән сүзләрдән, сүзтезмәләр һәм җөмләләр төзеп әйтү һәм язу. Тәкъдим ителгән җөмләләрне дөрес итеп күчереп язу. Алардагы *кем? нәрсә?* сорауларына җавап бирә торган сүзләрне табып әйтү. *Кая? кайда? кайдан?* сорауларына җавап биреп, әйбернең (кешенең) урыны турында хәбәр итү. Авазларны дөрес әйтү күнекмәләрен булдыру. Сингармонизм законы. Хәзерге заман хикәя фигыльләрне төрле затларда дөрес куллануга ирешү. –мы/ - ме кисәкчәле сүзләрне дөрес язарга күнектерү. |
| 2 | Ел фасыллары. Көз. | 11 | “Ел фасыллары” темасы буенча өйрәнелгән сүзләрне искә төшерү һәм, аларны кулланып, аралашуга күнектерү. Аерым рәсемнәр яки әйберләрне сурәтләп биргәндә, исем, сыйфат, фигыльләрне дөрес куллану. *Нинди?* соравына җавап биреп, әйбернең билгесен белдерү. Укучыларның монологик сөйләм күнекмәләрен үстерү. Чөнки теркәгече белән таныштыру |
| 3 | Көндәлек режим. | 12 | Сүзнең нигезе һәм кушымчасы. Өйрәнелгән сүзләрне һәм җөмлә калыпларын монологик сөйләмдә куллануга ирешү. *Сәгать ничә?* кебек калыпны гамәли үзләштерү. Микъдар саннарын кабатлау һәм 20гә кадәр санарга өйрәтү. Үткән заман хикәя фигыль белән таныштыру. |
| 4 | Чисталык һәм сәламәтлек. | 15 | Кеше әгъзаларын белдерә торган сүзләрне кабатлау. Алмашлыкларның килеш белән төрләнүен гамәли үзләштерү. *Кемгә? нәрсәгә?* Сораулары һәм аңа җавап. Диалогик һәм монологик сөйләмне үстерү. Исемнең күплек саны. |
| 5 | Безнең гаилә. | 27 | Гаилә кешеләре турында хәбәр итү. Гаилә кешеләренең һөнәре, белгечлеге турында хәбәр итү. Өйрәнелгән |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | | җөмлә калыпларын һәм сүзләрне сөйләмдә куллану. Исемнең төшем килеше белән төрләнеше. Исемнең күплек саны. Алмашлыкларның төрләнеше. Үткән заман хикәя фигыльнең юклык формасы. |
| 6 | Кыш. | 19 | “Ел фасыллары” темасы буенча өйрәнелгән сүзләрне искә төшерү һәм, аларны кулланып, аралашуга күнектерү. Аерым рәсемнәр яки әйберләрне сурәтләп биргәндә, исем, сыйфат, фигыльләрне дөрес куллану. *Нинди?* соравына җавап биреп, әйбернең билгесен белдерү. Укучыларның монологик сөйләм күнекмәләрен үстерү. Исемнәрнең күплек санын искә төшерү. Исемнәрнең тартым белән төрләнеше. Үткән заман хикәя фигыльне сөйләмдә куллану. |
| 7 | Яз . | 9 | “Ел фасыллары” темасы буенча өйрәнелгән сүзләрне искә төшерү һәм, аларны кулланып, аралашуга күнектерү. *Нинди?Кайчан?* соравына җавап биреп, әйбернең билгесен белдерү. Укучыларның монологик сөйләм күнекмәләрен үстерү. Татар телендә *о, ө* хәрефләренең беренчә иҗектә генә язылуын искә төшерү. Хәзерге заман хикәя фигыльнең барлык-юклык формалары. |
| 8 | Татарстан – туган җирем. | 7 | “Татарстан – туган җирем.” темасына бәйле сүзләрне һәм җөмләләрне искә төшереп, диалогик сөйләм оештыру күнекмәләрен активлаштыру. Ялгызлык һәм уртаклык исемнәре белән таныштыру. *Кайда?Кайдан?* соравына җавап бирү.Укучыларның монологик сөйләм күнекмәләрен үстерү. Хәзерге заман хикәя фигыльнең зат-сан белән төрләнеше. |
| 9 | Мин шәһәрдә һәм авылда. | 6 | Темага бәйле сүзләрне һәм җөмләләрне искә төшереп, диалогик сөйләм оештыру күнекмәләрен активлаштыру. Ялгызлык һәм уртаклык исемнәрен искә төшерү. Исемнәрнең тартым белән төрләнеше. Исемнәрнең юнәлеш, урын-вакыт һәм иялек килешләрендә кулланылуы. Үткән заман хикәя фигыльнең зат-сан белән төрләнеше. Аша, аркылы бәйлекләрнең сөйләмдә кулланылышы. |
| 10 | Мин авылда яшим. | 2 | Темага бәйле сүзләрне һәм җөмләләрне искә төшереп, диалогик сөйләм оештыру күнекмәләрен активлаштыру. Өйрәнелгән грамматик структуралар, фигыльләрнең зат-сан белән төрләнеше, җөмләдә сүзләр тәртибе. |
| 11 | Кибеттә. | 1 | “Кибеттә” темасына бәйле сүзләрне һәм җөмләләрне искә төшереп, диалогик сөйләм оештыру күнекмәләрен активлаштыру. Үткән заман хикәя фигыльнең барлык-юклык формасы. Исемнәрнең тартым |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | | белән төрләнеше. *Кая?* соравына җавап бирү. |
| 12 | Җәй. | 8 | “Ел фасыллары” темасы буенча өйрәнелгән сүзләрне искә төшерү һәм, аларны кулланып, аралашуга күнектерү. *Нинди?Кайчан?* соравына җавап биреп, әйбернең билгесен белдерү. Җөмләдәге сүзләргә сораулар кую, саннарны сөйләмдә куллану. Фигыльләрнең хәзерге һәм үткән заман формасы. Килеш сораулары. |

«РАССМОТРЕНО»
Руководитель ШМО
______________/Минубаева М.Н./
Протокол №1 от «27» августа 2022 г.

«СОГЛАСОВАНО»
Зам. директора по УР
____________/Зиганшина М.И./
«29» августа 2022 г.

«УТВЕРЖДАЮ»
Директор МБОУ «Лашманская СОШ»
__________/Нуртдинов Н.Р./
Приказ № 25 от «31» августа 2022 г.

**КАЛЕНДАРНО-ТЕМАТИЧЕСКОЕ ПЛАНИРОВАНИЕ**
**К АДАПТИРОВАННОЙ РАБОЧЕЙ ПРОГРАММЕ**

по учебному предмету «Родной (татарский) язык и родная (татарская) литература»
5 класс
учителя I квалификационной категории
МБОУ «Лашманская СОШ»
Черемшанского муниципального района Республики Татарстан
Гайсиной Гузалии Идрисовны

**Татар теле һәм әдәби укудан календарь- тематик план**

| № | Дәрес темасы | Дәрес тибы | Сәгать саны | Укучылар эшчәнлегенә характеристика яки уку эшчәнлегенең төре | Контроль төре | Көтелгән нәтиҗә | Число | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | План буенча | Факт |
| | **Яңа уку елы белән! (11 сәгать)** | | | | | | | |
| 1 | Яңа уку елы белән! | ЛГКК | 1 | | | | | |
| 2 | Хәзерге заман хикәя фигыльнең юклык формасы. | ГКФ | 1 | Бәйрәм, котлыйм.<br>Сөт эчә. | | Хәзерге заман хикәя фигыльнең III зат юклык формасы: укы-мый, кил-ми. | | |
| 3 | Сорау белдерүче аффикслар –мы/-ме | ГКК | 1 | Шигыр сөйли. | Исемнәрнең I, II, III затта берлек санда төрләнеше. | Сорау аффикслары<br>-мы/ -ме. | | |
| 4. | Татар телендә сингармонизм законы. | ГКК. | 1 | Башлана. | Татар телендә сингармонизм законы. | Сузык аваз, тартык авазлар. Татар теленә генә хас авазлар: [ә], [ү], [w], [ө], [ң], [h], [ж], [г], [к] h.б. | | |
| 5. | Кая? Кайда? сорауларына җавап формасы. | ГКФ | 1 | Бара, кайта. | | Кая? кайда? сорауларына җавап бирү,<br>-га/-гә,-ка/-кә, -да/-дә, -та/-тә кушымчаларының дөрес язылышы. | | |
| 6 | Кайдан? соравына җавап формасы. | ГКК | 1 | | | Кайдан? соравына җавап булган сүзләрдә кушымчаларның | | |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | дөрес язылышы. | | |
| 7. | Исемнәрнең берлектә тартым белән төрләнеше. | ГКК | 1 | Уку-язу әсбаплары исемнәре. | | Исемнәрнең берлектә тартым белән төрләнеше. | | |
| 8. | Хәзерге заман хикәя фигыльнең зат белән барлык-юклык формасында төрләнеше.( Сүзлек диктанты) | ГКФ | 1 | Тырыш, сорау бирә, җавап бирә, хата төзәтә, күнегү эшли, билге куя. | | Хәзерге заман хикәя фигылҗнең зат белән барлык-юклык формасында төрләнеше. | | |
| 9 | “Безнең сыйныфта” тексты. | ЛГКК | 1 | | Хәзерге заман хикәя фигыльнең III зат барлык-юклык формасы. Нишлибез? Нишләмибез? | | | |
| 10. | Алмашлыклар. | ГКК | 1 | Мин, син, ул, без, сез, алар. | | | | |
| 11. | Мәктәптә зур бәйрәм. | ГКК. | 1 | Бәйрәм, кунаклар, каршылый. Дәвам итә, тәрҗемә итә. | Сорау алмашлыкларына басымның куелышы. | | | |
| | **Ел фасыллары. Көз. (6 сәгать)** | | | | | | | |
| 12. | “Көз җитте”. | ЛКФ | 1 | Кошлар, йөгерә, урам, җил, җылы, ява, көчле, урман, яңгыр, салкын. Көз көне, төн, кыска, озын, яфрак, исә, җылы як. | Нинди? соравына җавап бирә белү. | ө, о хәрефләрнең дөрес язылышы. | | |
| 13. | Нинди? соравына җавап формасы. | ЛКФ | 1 | Көз көне, төн, кыска, озын, яфрак, исә, җылы як. | Нинди? соравына җавап бирә белү. | | | |
| 14. | Җиләк-җимеш яратам. | ЛКФ | 1 | Кызыл чия, баллы груша, тәмле слива, яшел алма, | Нинди? соравына җавап | | | |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | кара карлыган, сары миләш.<br>Ачы. | бирә белү.<br>Исемнең берлек-күплек саны. | | | |
| 15. | “Базарда” тексты өстендә эшне дәвам итү. | ЛГКК | 1 | Кайта, күп, бара, сатып ала.<br>Бай, түгәрәк. | Кая? кайда? кайдан? сорауларына җавап бирү. | | | |
| 16. | “Көз” тексты. | ЛКФ | 1 | Елга, көз көне.<br>Ай, эссе, кара каргалар, алтын, оя ясый, җылыта, җылы як, җәнлекләр, кыздыра. | | | | |
| 17. | Чөнки теркәгече. | ГКК | 1 | Коена, ярата, ява, яшелчә бакчасы, ясый, йөри, яшелчәләр.<br>Чөнки | Җөмләдә сүзләр тәртибе | Чөнки теркәгече белән җөмләләр төзү, сөйләмдә куллану. | | |
| | **Көндәлек режим. (7 сәгать)** | | | | | | | |
| 18 | Сүзнең нигезе һәм кушымчасы. | ГКФ | 1 | Китә, ята, йөзә, килә, оча, сикерә. | | Сүзнең нигезе һәм кушымчасы. | | |
| 19 | Үткән заман хикәя фигыль. | ГКФ | 1 | Хата ясады, сорау бирде. | | Үткән заман хикәя фигыль. | | |
| 20 | Үткән заман хикәя фигыль. | ГКК | 1 | Йөзде, булышты, барды, әйтте.<br>Торды, зарядка ясады. | | Сингармонизм законы. | | |
| 21. | “Мин вакытны әйтә беләм”. | ГКК | 1 | Сәгать, дәрес әзерли, сәгать ничәдә? Сәгать икедә, йокы. | Нишли? нишләде? Сорауларына җавап бирү. | Сәгать икедә - структурасын сөйләмдә куллану. | | |
| 22. | Мин санарга өйрәнәм. | ЛКК | 1 | 1дән 100гә кадәр саннар. | | 1дән 100гә кадәр саннар. | | |
| 23. | “Көндәлек режим” темасын кабатлау. | ЛКК | 1 | “Көндәлек режим” темасы лексикасы. | | | | |
| 24. | Контроль күчереп язу №1 “Көндәлек режим”. | ЛГКК | 1 | | | | | |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | **Чисталык һәм сәламәтлек. (7 сәгать)** | | | | | | | |
| 25. | “Аның” – алмашлыгы. | ЛГКК | 1 | | Аның – алмашлыгы. | | | |
| 26. | “Минем, синең, аның” – алмашлыклары. | ЛГКК | 1 | | Минем, синең, аның – алмашлыклары. | | | |
| 27. | Без походка барабыз. | ЛГКК | 1 | Элгеч, ята, тора, җир, сөлге, сабын.<br>Иртәгә. | Исемнәрнең берлек санда тартым белән төрләнеше. | Тартым кушымчалары ялганда [п]-[б] авазларның чиратлашуы. | | |
| 28. | Табиб янында. | ЛГКК | 1 | Дару, җылы сөт, кирәк (-ме).<br>Температураңны кара, авырта, үлчи. | 20-100гә кадәр саннар. | | | |
| 29. | Без урамда уйныбыз. | ЛГКК | 1 | Шаярта, күңелле көлә, эчә, дару, эш, файдалы. | Башы авырта структурасын кабатлау, чөнки теркәгечен сөйләмдә куллану. | | | |
| 30. | Кемгә? Нәрсәгә? сораулары һәм аңа җавап. | ГКФ | 1 | Кая?<br>Кемгә? Нәрәгә? | | Кемгә? нәрсәгә? Сораулары һәм аңа җаваплар. | | |
| 31. | Сүзлек диктанты №1. | ЛГКК | 1 | | | | | |
| | **Безнең гаилә. (13  сәгать)** | | | | | | | |
| 32. | Исемнең күплек саны. | ЛКФ | 1 | Иртәнге аш, көндезге аш, кичке аш, онык. | -лар/-ләр,<br>-нар/-нәр кушымчалары. | | | |
| 33. | Исемнең төшем килеше белән төрләнеше. | ГКФ | 1 | | Исемнең төшем килеше белән төрләнеше. | | | |
| 34. | Исемнең төшем килеше белән төрләнеше. | ГКФ | 1 | | Исемнең төшем килеше белән төрләнеше. | | | |
| 35 | “Әни табын әзерли” | ЛКФ | 1 | | Исемнәрнең | | | |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | хикәясе. | | | | төшем килеше белән төрләнеше. | | | |
| 36. | Алмашлыкларның төрләнеше. | ГКФ | 1 | Чынаяк, пычак, әзерли, чәнечке, эшчән, булыша, юа, сөртә, куя. | | | | |
| 37. | Нәрсәне? соравы һәм аңа җавап. | ЛКФ | 1 | | Нәрсәне? соравы һәм аңа җавап. | | | |
| 38. | “Ял көне” хикәясендәге яңа сүзләр. | ЛКФ | 1 | Иртән, кич белән, аннан соң, иртәнге аш, кичке аш. Ял көне, бергә, саф һава, ял итә. | Исемнәрнең юнәлеш, төшем, чыгыш килешләрендә төрләнүе. | | | |
| 39. | “Айдар бездә кунакта” хикәясе. | ЛКФ | 1 | өчпочмак, җыештырды. | | | | |
| 40. | Табын янында. | ГКК | 1 | Ватты, коймак, кыстыбый, гөбәдия. | Хәзерге заман хикәя фигыльнең зат-сан белән төрләнеше. | | | |
| 41. | Диктант №1 “Безнең гаиләдә”. | ЛГКК | 1 | Юа, җыя,сөртә. | Үткән  заман хикәя фигыльнең зат-сан белән төрләнеше. | | | |
| 42 | Үткән заман хикәя фигыльнең юклык формасы. | ГКК | 1 | Чынаяк, пычак, кибет, кашык, май. | | | | |
| 43 | Үткән заман хикәя фигыльнең юклык формасы: бармады. | ГКК | 1 | Чынаяк, пычак, кибет, кашык, май. Кача. | | | | |
| 44 | Монолог төзү. | ГКК | 1 | “Безнең гаилә” темасына кергән сүзләр. | | | | |
| | **Кыш. (9 сәгать)** | | | | | | | |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 45 | “Без кошларга булышабыз” хикәясе. | ЛКФ | 1 | Тукран, авыр, песнәк, ала каргач. | | | | |
| 46 | Яңа ел бәйрәме. | ЛКФ | 1 | Котлый, чыршы, кыш бабай, бәйрәм, җыр, яңа ел, нарат. | Сыйфат һәм исемнәрнең сораулары. | Яңа елга котлау тексты язу. | | |
| 47 | Яңа ел. | ЛКФ | 1 | Яңа ел. | Сыйфат һәм исемнәрнең сораулары. | | | |
| 48 | “Чыршы бәйрәме”. | ЛКФ | 1 | Башлана, яңа ел, уку елы, бәйрәм, чыршы.<br>Чыршы бәйрәме, була, бию, өченче. | Рус биюе, куян булып киенә төзелмәләре. | Тәртип саннарын сөйләмдә куллану. | | |
| 49 | Кая? нишләде? Сораулары. | ЛКФ | 1 | Чыршы, бәйрәм.<br>Тимераяк, чаңгы, күңелле, чана, тау, авыр, кәшәкә таягы. | -га/-гә, -ка/-кә, -ды/-де, -ты/-те кушымчалары. | | | |
| 50 | Кышкы уеннар. | ЛГКК | 1 | Тимераяк, чаңгы, күңелле, чана, тау, авыр, кәшәкә таягы. | Исемнәрнең тартым белән төрләнеше. | | | |
| 51 | Кышкы көн. | ЛКФ | 1 | Тау, кар бабай, чаңгы, чана, тимераяк.<br>Җимлек. | Исемнәрнең тартым белән төрләнеше. | | | |
| 52 | “Тауда” хикәясе. | ЛКФ | 1 | Тау, шатланды, кар бабай. | Өйрәнелгән фигыль формалары.<br>Чөнки теркәгечен җөмлә эчендә куллану. | Һәм теркәгечен сөйләмдә куллану. | | |
| 53 | “Кыш” циклын кабатлау. | ЛГКК | 1 | | | | | |
| **Яз. (4 сәгать)** | | | | | | | | |
| 54 | Ел фасылы – яз. | ЛКФ | 1 | Елга, кием- салым исемнәре, кояш, сыерчык, чыпчык.<br>Чагыла, киез итек, эре, | Кайчан? Соравына җавап булган сүзләрне сөйләмдә | | | |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | тамчы. | куллану. | | | |
| 55 | Язгы табигать. | ЛКФ | 1 | Җылы, сайрый, озын, кыска.<br>Ямьле, боз китә. | Хәзерге заман хикәя фигыльнең барлык-юклык формалары. | | | |
| 56 | Язгы көннәр. | ЛКФ | 1 | Йорт кошлары, урман кошлары, сандугач, әтәч, үрдәк, песнәк. | Капма-каршы мәгънәле сүзләр. | Татар телендә о, ө хәрефләренең беренче иҗектә генә язылуы. | | |
| 57 | Бәйрәмнәр. | ЛГКК | 1 | 8нче Март бәйрәме, Яңа ел бәйрәме, 1нче Май бәйрәме, Белем  көне, Сабантуй, бүләк. | Кайчан? Соравына җавап бирү. | | | |
| | **Татарстан – туган җирем. (3 сәгать)** | | | | | | | |
| 58 | Татарстан – туган җирем. | ЛКФ | 1. | Татарстан шәһәрләре исемнәре, елга исемнәре. Туган як, туган җир, Агыйдел, Идел. | Өйрәнелгән фигыль формалары. | Ялгызлык һәм уртаклык исемнәре. | | |
| 59 | Татарстан республикасы. | ЛКФ | 1 | Татарстан, республика, Казан, Әлмәт. | Ялгызлык һәм уртаклык исемнәре. | | | |
| 60 | Татарстан республикасы. | ЛКФ | 1 | | Ялгызлык һәм уртаклык исемнәре. | | | |
| | **Мин шәһәрдә һәм авылда яшим. (4 сәгать)** | | | | | | | |
| 61 | Мин шәһәрдә яшим. | ГКФ | 1 | Трамвай, шәһәр, бара, автобус, авыл.<br>Казан шәһәре, Поспелово авылы. | Ялгызлык һәм уртаклык исемнәр. Исемнәрнең тартым белән төрләнеше. | Казан шәһәре, автобус белән барам структураларын сөйләмдә куллану. | | |
| 62 | “Казан кунагы” тексты. | ЛКФ | 1 | Башкала, Казан турында, кунак, ерак, монда, таныш. | | | | |
| 63 | “Юлда” тексты. | ЛКФ | 1 | Светофор, чыга, яшел, кызыл, сары, шатлана, | Үткән заман хикәя | Аша, аркылы бәйлекләрнең | | |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | тукталыш, туктый, юл аша, яна, саклый, елмая. | фигыльнең зат-сан белән төрләнеше. | сөйләмдә кулланылышы. | | |
| 64 | Юл кагыйдәләре. | ЛКФ | 1 | Светофор, чыга, аша, яшел, кызыл, сары, юл. | | | | |
| | **Җәй. (6 сәгать)** | | | | | | | |
| 65 | Ел фасылы – җәй. | ЛКФ | 1 | Эссе, озын, кыска, сайрый, кош, бетте, башланды. Җәйге, кыздыра, болын. | Җөмләдәге сүзләргә сораулар кую, саннарны сөйләмдә куллану. Кайчан? Соравын сөйләмдә куллану. | | | |
| 66 | Г. Тукай. “Бала белән күбәләк” шигыре. | ЛГКК | 1 | Якты, бай, сөйләм, ошый, шигырь, биек. Армыйсың, бергәләп, бөек, сөйләшә, шагыйрь. | | | | |
| 67 | Контроль күчереп язу | контроль | 1 | | | | | |
| 68 | Хаталар өстендә эш.Кабатлау | | 1 | | | | | |
| 69 | Үткәннәрне кабатлау | | 1 | | | | | |
| 70 | Гомумиләштереп кабатлау | | 1 | | | | | |

## ӘДӘБИ УКУДАН УКЫТУ ПРОГРАММАСЫ

| № | Дәрес темасы | Дәрес тибы | Сәгать саны | Укучылар эшчәнлегенә характеристика яки уку эшчәнлегенең төре | Контроль төре | Көтелгән нәтиҗә | Число | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | План буенча | Факт |
| | **Яңа уку елы белән! (12сәгать)** | | | | | | | |
| 1. | Яңа уку елы белән! | ЛГКК | 1 | Исәнләшү, саубуллашу лексикасы. Уку-язу әсбаплары исемнәре | Миңа, сиңа, алмашлыклары, китап кирәк (кирәкми) структурасы. | | | |
| 2. | Бүген бәйрәм. | ЛГКК | 1 | Бәйрәм, котлыйм. | | | | |
| 3 | Беренче сентябрь – зур бәйрәм. | Диалогик, монологик сөйләм. | 1 | | Хәзерге заман хикәя фигыльнең III зат юклык формасы. | | | |
| 4. | Татар телендә хәреф-аваз системасы. | ЛГКК. | 1 | Сорау, нокта, аваз, сузык, өтер, хәреф, тартык. | | | | |
| 5. | Кая? Кайда? сорауларына җавап формасы. | ЛГКК | 1 | | | | | |
| 6. | Кайдан? соравына җавап формасы. | ЛГКК | 1 | | | | | |
| 7. | Диалоглар төзү. | Диалогик сөйләм. | 1 | | | | | |
| 8. | Монологлар төзү. | Монологик сөйләм | 1. | | | | | |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | . | | | | | | |
| 9. | “Безнең сыйныфта” тексты. | Монологик сөйләм. | 1. | | | | | |
| 10. | “Безнең сыйныфта” текст өстендә эшне дәвам итү. | Монологик сөйләм. | 1. | | Хәзерге заман хикәя фигыльнең юклык формасы: укымыйбыз, сөйләмибез, яшәмибез. | | | |
| 11. | Б. Рәхмәт “Мәктәптә” шигыре. | ЛГКК | 1 | Юл, дәү, зур, икеле, белә, өйрәтә. | Хәзерге заман хикәя фигыльнең зат-сан белән, барлык-юклык белән төрләнеше. | | | |
| 12. | “Яңа уку елы белән” темасын кабатлау. | Диалогик, монологик сөйләм. | 1 | | | | | |
| | **Ел фасыллары. Көз. (5 сәгать)** | | | | | | | |
| 13. | Мин көз турында сөйлим. | Диалогик, монологик сөйләм. | 1 | Уку елы, дустым белән, җылы як, көз көне. Сөйләмне бәяләү критерийлары. | | | | |
| 14. | “Базарда” тексты. | Диалогик, монолог | 1 | | Нишли? соравына җавап бирү. | | | |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | гик сөйләм. | | | | | | |
| 15. | Г. Гәрәева “Көз һәм балалар җыры” шигыре. | ЛГКК | 1 | Алтын көз, суык, салкын. | Кайда? соравына җавап бирү. Исемнәрнең тартым белән төрләнеше (минем, синең, аның). | Бир әле, бирегез әле – төзелмәләре. | | |
| 16. | “Көз” тексты өстендә эшне дәвам итү. | Диалогик, монологик сөйләм. | 1 | “Көз” темасына караган лексика. | Җөмләдәге сүзләргә сорау кую. | | | |
| 17. | “Көз җитте” циклын кабатлау. | Диалогик, монологик сөйләм. | 1 | | | | | |
| | **Көндәлек режим. (5 сәгать)** | | | | | | | |
| 18. | Монолог төзү. | Монологик сөйләм. | 1 | | | | | |
| 19. | М. Җәлил “Сәгать” шигыре. | Монологик сөйләм. | 1 | | Аннан соң, файдалы. | Җөмләдә сүз тәртибе. | | |
| 20. | Мин бүген нишләдем? | Диалогик, монологик | 1 | Сәгать ничәдә? Тор, кара, сикер, кайт, дәрес әзерлә. | Үткән заман хикәя фигыльнең берлек санда зат | Үткән заман хикәя фигыльнең берлек санда зат белән төрләнеше. | | |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | сөйләм. | | | белән төрләнеше. | | | |
| 21 | Минем бер көнем (көндәлек режим). | Монологик сөйләм. | 1 | “Көндәлек режим” темасы лексикасы. | Хәзерге һәм үткән заман хикәя фигыльнең зат-сан белән төрләнеше. | | | |
| 22. | “Көндәлек режим” темасын кабатлау. | Диалогик, монологик сөйләм. | 1 | “Көндәлек режим” темасы лексикасы. | | | | |
| | **Чисталык һәм сәламәтлек. (8 сәгать)** | | | | | | | |
| 23. | “Алсу – пөхтә кыз” хикәясе. | ЛКФ | 1 | Чиста, тарый, юына, чистарта.<br>Тагын, сөртә, иртән, пөхтә, көндез, йомшак. | | Сабын белән юына щетка белән теш чистарта структураларын сөйләмдә куллану. | | |
| 24. | “Алсу – пөхтә кыз” хикәясе. | Диалогик, монологик сөйләм. | 1 | | | | | |
| 25. | “Акыллы малай” хикәясе. | Диалогик,монологик сөйләм. | 1 | Файдалы, көндез, әатлана, аннан соң, рәхмәт әйтә, булыша, мактый, киенә. Акыллы, урын җыя. | Аның әнисе – структурасы. | - Син акыллы малай!<br>- Син нинди пөхтә!<br>- Син яхшы кыз! – кебек мактау формалары. | | |
| 26. | Тән әгъзалары | ЛКФ | 1 | Чәч, күз, ирен, бит, авыз, | Исемнәрнең | Исемгә кушымча | | |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | исемнәре. | | | каш, колак, баш, борын, муен. | берлек санда тартым белән төрләнеше. | ялгаганда авазлар чиратлашуы: [к]-[г]. | | |
| 27. | Минем тән әгъзаларым. | Диалогик, монологик сөйләм. | 1 | | Исемнәрнең күплек саны. Минем (синең)+ исем конструкциясе. | | | |
| 28. | Табиб янында. | Диалогик, монологик сөйләм. | 1 | | | | | |
| 29. | Без урамда уйныбыз. | Диалогик, монологик сөйләм. | 1 | | | | | |
| 30. | “Чисталык һәм сәламәтлек” циклын кабатлау. | Диалогик, монологик сөйләм. | 1 | | | | | |
| | **Безнең гаилә. (14 сәгать)** | | | | | | | |
| 31. | Минем гаиләм. | Диалогик, монологик сөйләм. | 1 | Әни, әти, бабай, әби, апа, абый. | | | | |
| 32. | Ә. Бикчәнтәева, тормыш юлы һәм | Моно логик | 1 | | | | | |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | иҗаты. | сөйлә м. | | | | | | |
| 33 | Ә. Бикчәнтәева “Дәү әнием” шигыре. | ЛГКК | 1 | Бәлеш, гөбәдия, чәкчәк, өчпочмак. Үстерә, озак, кадерле. | | | | |
| 34. | Ш. Маннур, тормыш юлы һәм иҗаты. | Моно логик сөйлә м. | 1 | | | | | |
| 35. | Ш. Маннур “Яратам” шигыре. | ЛГКК | 1 | Эне, бакча, өй, сеңел, иптәш. | | | | |
| 36. | Ш. Галиев, тормыш юлы һәм иҗаты. | Моно логик сөйлә м. | 1 | | | | | |
| 37. | “Ял көне” хикәясе. | ЛГКК | 1 | Кичке аш, иртән, кич, ял көне, көндез, кайчан? | Җөмләдә сүзләр тәртибе. Фигыльнең I-II зат күплек саны. | | | |
| 38. | “Ял көне” тексты өстендә эш. | Диал огик, моно логик сөйлә м. | 1 | | | | | |
| 39. | “Айдар бездә кунакта” хикәясе. | Диал огик, моно логик сөйлә м. | 1 | | Итагатьле сүзләрне сөйләмдә куллану. | | | |
| 40. | Мин кунак көтәм. | Диал огик, моно логик сөйлә | 1 | | | | | |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | м. | | | | | | |
| 41. | А. Алишның тормыш юлы һәм иҗаты. | ЛГКК | 1 | | | | | |
| 42. | А. Алиш әкиятләре. | ЛГКК | 1 | Әкият. | | | | |
| 43 | “Безнең гаилә” циклын кабатлау. | ЛГКК | 1 | | | | | |
| 44 | “Безнең гаилә” циклын кабатлау. | ЛГКК | 1 | | | | | |
| | **Кыш. (10 сәгать)** | | | | | | | |
| 45 | Ел фасылы – кыш. | ЛГКК | 1 | Ел фасылы, кыш, айлар исеме, салкын. | | | | |
| 46 | Кошлар. | ЛГКК | 1 | Күгәрчен, карга, песнәк, тукран, чыпчык. | | | | |
| 47 | “Без кошларга булышабыз” хикәясе. | ЛГКК | 1 | Тукран, авыр, песнәк, ала каргач. | | | | |
| 48 | С. Сабированың тормыш юлы һәм иҗаты. | ЛГКК | 1 | | | | | |
| 49 | С.Сабирова. “Кыш бабай җыры” шигыре. | ЛГКК | 1 | Котлый, чыршы, кыш бабай, бәйрәм, җыр, яңа ел, нарат.<br>Таныш, дус, бәхет, тели. | | | | |
| 50 | “Чыршы бәйрәме” тексты. | ЛГКК | 1 | Чыршы бәйрәме, була, бию, өченче. | | | | |
| 51 | Без тауга барабыз. | Диалогик, монологик сөйләм. | 1 | Тимераяк, чаңгы, күңелле, чана, тау, авыр, кәшәкә таягы. | | Ә теркәгечен сөйләмдә куллану. | | |
| 52 | “Каникулда” хикәясе. | ЛГКК | 1 | Рәхмәт әйтте, көтте, рәхәт булды, бүләк итте.<br>Якын, әбәкле уены. | Үткән заман хикәя фигыльне сөйләмдә куллану. | | | |
| 53 | “Тауда” хикәясе. | ЛГКК | 1 | Тау.<br>Шатланды, кар бабай. | | | | |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 54 | “Тауда” хикәясе өстендә эшне дәвам итү. | Диалогик, монологик сөйләм. | 1 | Тәрбияле, саран, юмарт, риза, риза түгел. | Капма-каршы мәгънәле сүзләр. фигыльләрнең барлык-юклык формасы. | Риза, риза түгел төзелмәләре. | | |
| **Яз. (5 сәгать)** | | | | | | | | |
| 55 | Ф. Кәрим тормыш юлы һәм иҗаты. | ЛГКК | 1 | | | | | |
| 56 | Ф. Кәрим. “Яз җитә” шигыре. | ЛГКК | 1 | Елга, кием- салым исемнәре, кояш, сыерчык, чыпчык, чагыла, киез итек, эре, тамчы | | | | |
| 57 | “Яз” хикәясе. | ЛГКК | 1 | Җылы як, сайрый, оя куйды, тырыш, озын, эри, кыска, ямьле, боз китә. | Хәзерге заман хикәя фигыльнең барлык-юклык формалары. | | | |
| 58 | “Яз” хикәясе өстендә эшне дәвам итү. | Диалогик, монологик сөйләм. | 1 | Йорт кошлары, урман кошлары, сандугач, әтәч, үрдәк, песнәк. | | | | |
| 59 | 8нче Март - әниләр бәйрәме. | ЛГКК | 1. | 8нче Март бәйрәме, бүләк. | | 8нче Март бәйрәме белән котлау язу. | | |
| | **Татарстан – туган җирем. (4 сәгать)** | | | | | | | |
| 60 | Туган ягым. | Диалогик, монологик сөйләм. | 1 | Татарстан шәһәрләре исемнәре, елга исемнәре, кыргый хайван исемнәре,туган як, туган җир, Агыйдел, Идел | | | | |
| 61 | Мин кайда яшим? | Диалогик, монологик | 1 | | Кайда? Кайдан? сораулары. | | | |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | сөйләм. | | | | | | |
| 62 | Ә. Рәшитовның тормыш юлы һәм иҗаты. | ЛГКК | 1 | | | | | |
| 63 | Ә. Рәшитов. “Кояшлы ил” шигыре. | ЛГКК | 1 | Район, шәһәр, шигырь. | | | | |
| | **Мин шәһәрдә һәм авылда яшим. (2 сәгать)** | | | | | | | |
| 64 | Казан шәһәре. | Монологик сөйләм. | 1 | Казан, шәһәр. | Ялгызлык һәм уртаклык исемнәре. | | | |
| 65 | Мин кайда яшим? | ЛГКК | 1 | Татарстан шәһәрләре исемнәре. | Исемнәрнең юнәлеш, урын-вакыт һәм иялек килешләрендә кулланылуы. | | | |
| | **Мин авылда яшим. (2 сәгать)** | | | | | | | |
| 66 | “Мин авылда яшим” хикәясе. | ЛГКК | 1 | Янында, җиләк, кызына, тау, рәхәт, җәй көне, су коена. | | | | |
| 67 | М. Җәлил. “Әтәч” шигыре. | ЛГКК | 1 | Әтәч. | | | | |
| | **Кибеттә. (1 сәгать)** | | | | | | | |
| 68 | Киемнәр кибетендә. Ашамлыклар кибете. | ЛГКК | 1 | Итек, итәк, яулык, читек, бияләй, ошый, сатып ала, киеп карый, т Май, ашый, ботка, пешерә, аш, кирәк, ашамлык, шикәр, йомырка, ярма, катык, он, тоз.үли, сайлый. | | Киемнәр, ашамлыклар кибетенә барам структурасын сөйләмдә куллану. | | |
| | **Җәй. (2 сәгать)** | | | | | | | |
| 69 | “Җәй житте” хикәясе. Сабантуй – күңелле бәйрәм. | ЛГКК | 1 | Эссе, озын, кыска, сайрый, кош, бетте, башланды, ял итә, булыша, җәйге, кыздыра, болын.<br>Ямьле, рәхәт, көрәшә, сабантуй, урман янында, рус | | | | |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | биюе, күңелле, ярыша, көрәшә, атлар чаба, баганага менә, чүлмәк вата. | | | | |
| 70 | Ш. Галиев. “Жираф белән Зариф” шигыре. Йомгаклау дәресе | Диалогик, монологик сөйләм. | 1 | Ерак, кыска, күрә, муен, озын, кара. | | | | |

# ***Укучыларның белем дәрәҗәсенә таләпләр.***

1.Татар теленең төп фонетик үзенчәлекләрен, татар теленә генә хас булган фонемаларның дөрес әйтелешен гамәли үзләштерү.

2.Татар телендә сүз басымын дөрес куя һәм иҗек чигендәге фонетик үзгәрешләрне истә тотып сөйли белү күнекмәләрен ныгыту.

3. Актив үзләштерелгән лексик берәмлекләрне дөрес язу.

4.Татар һәм рус телләрендә сүз тәртибенең үзенчәлекләрен аера, аңлый белү һәм тәрҗемә итү үзенчәлекләрен гамәли үзләштерү.

5.Орфоэпик һәм орфографик яктан сөйләмне дөрес оештыру, програмада каралган язма эшләрне грамоталы башкара белү.

6.Татар сөйләмен өйрәнелгән лексика һәм грамматика кысаларында аңлый һәм диалогик, монологик сөйләм аша аралаша белү күнекмәләрен ныгыту.

7. Тыңлап аңлау. Татар сөйләмен ишетеп аңлау, текстны аңлап, сорауларга җавап бирү күнекмәләрен формалаштыру һәм ныгыту.

8. Диалогик сөйләм. Диалог төзү, текст буенча әңгәмә кору, үрнәк буенча диалог төзи белү күнекмәләрен ныгыту.

9. Монологик сөйләм. Ситуация буенча хикәя төзү, текстның төп эчтәлеген сөйләү, сюжетлы рәсем буенча хикәя төзү күнекмәләрен ныгыту.

10. Уку. Текстны сәнгатле, аңлап уку, эчтәлегенә төшенү, сүзлек белән эшләү, яттан сөйләм күнекмәләрен ныгыту.

# *Татар теле һәм укудан белем һәм күнекмәләрне бәяләү нормалары.*

| **1. Диалогик сөйләмне бәяләү** | |
|---|---|
| **Диалогта репликалар саны - 4** | **Билге** |
| Бирелгән ситуация яки тема буенча әңгәмә кора алганда, әйтелеше һәм грамматик төзелеше ягыннан дөрес, эчтәлеге эзлекле һәм тулы диалогик сөйләм төзегәндә | «5» |
| Бирелгән ситуация яки тема буенча әңгәмә кора алганда, әмма репликаларның әйтелешендә һәм аерым сүзләрдә 2-3 хата җибәреп эзлекле диалогик сөйләм төзегәндә | «4» |
| Өстәмә сораулар ярдәмендә генә әңгәмә кора алганда, 4-6 хата җибәреп, эчтәлеген бозып диалогик сөйләм төзегәндә | «3» |
| Бирелгән ситуация яки тема буенча диалог төзи алмаганда | «2» |
| **2. Монологик сөйләмне бәяләү** | |
| **Монологик сөйләмдә фразалар саны - 5** | **Билге** |
| Өйрәнелгән яки тәкъдим ителгән тема буенча әйтелеше, грамматик төзелеше ягыннан дөрес һәм эчтәлеге ягыннан тулы, эзлекле монологик сөйләм өчен | «5» |
| Өйрәнелгән яки тәкъдим ителгән тема буенча эзлекле төзелгән, әмма аерым сүзләрнең әйтелешендә, грамматик формаларында яки җөмлә төзелешендә 2-3 хатасы булган сөйләм өчен- | «4» |
| Өйрәнелгән яки тәкъдим ителгән тема буенча эзлекле төзелмәгән, 4-6 хатасы булган сөйләм өчен | «3» |
| Өйрәнелгән яки тәкъдим ителгән тема буенча монолог төзи алмаганда | «2» |

| 3. Укуны бәяләү | |
|---|---|
| **Уку тизлеге – 30-35 сүз** | **Билге** |
| Текстның эчтәлеген тулаем аңлап,авазларны дөрес әйтеп, басымны дөрес куеп, сәнгатьле һәм аңлаешлы итеп тиешле тизлектә укыганда | «5» |
| Текстның эчтәлеген аңлап, сәнгатьле һәм аңлаешлы итеп, әмма тупас булмаган 2-3 орфоэпик хата җибәреп укыганда | «4» |
| Текстның эчтәлеген өлешчә аңлап, 4-6 тупас орфоэлик хата җибәреп укыганда һәм уку тизлеге акрын булганда | «3» |
| Текстның эчтәлеген аңламыйча, 7 дән артык хата җибәреп һәм уку тизлегенә куелган таләпләрне үтәмичә укыганда | «2» |
| **5. Язма эшләрне бәяләү.** | |
| **Контроль күчереп язу (җөмләләр саны) – 3-4** | **Билге** |
| Пөхтә, төгәл һәм орфографик хатасыз эшкә | «5» |
| Пөхтә, төгәл язылган, әмма 1-3 төзәтүе яки 1-2 орфографик хатасы булган эшкә | «4» |
| Пөхтә һәм төгәл язылмаган , 4-5 төзәтүе яки 3-5 орфографик хатасы булган эшкә | «3» |
| Пөхтә һәм төгәл язылмаган, 6 яки артыграк хатасы булган эшкә | «2» |
| **Диктант (сүзләр саны) – 25-30**<br>**Сүзлек диктанты (сүзләр саны)- 6-7** | **Билге** |
| Пөхтә, төгәл язылган, 1 орфографик хатасы булган диктантка | «5» |
| Пөхтә, төгәл язылган, 2-3 орфографик хатасы булган диктантка | «4» |
| Пөхтә, төгәл язылмаган, 4-6 орфографик хатасы булган диктантка | «3» |

| | |
|---|---|
| Пөхтә, төгәл язылмаган, 7 яки артыграк хатасы булган диктантка | «2» |
| **6. Тыңлап аңлауны бәяләү** | |
| Тыңлап аңлау (минутларда) -0,5 - 1 | **Билге** |
| Тыңланган татар сөйләмен тулаем дөрес аңлап, эчтәлеген сөйли алганда | «5» |
| Тыңланган татар сөйләмен аңлап, эчтәлеген якынча сөйли алганда | «4» |
| Тыңланган татар сөйләмен аңлап,эчтәлеген өлешчә сөйли алганда | «3» |
| Тыңланган татар сөйләмен аңламаганда | «2» |